ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 73-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатлары М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 73-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 11 июне
№ 308-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутатлары
М.Һ. Галиев, Р.Г. Хөсәенов
тарафыннан кертелә

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында**

# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4, № 10 (I өлеш); 2016, № 10; Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2019, № 49 (I өлеш); 2020, № 1 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 77 (I өлеш); 2023, № 27 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 34 (I өлеш), № 45 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 өлештә «дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар,» сүзләрен «әлеге статьяның $3^1$ өлеше нигезендә урнаштырылырга тиешле дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар,» сүзләренә алмаштырырга;

2) $3^1$ өлештә «Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турында карар,» сүзләрен «Дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында» 2001 елның 21 декабрендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законның 13 статьясындагы 1 пунктның 1, $1^1$, 5, 9, һәм 10 пунктчаларында каралган ысуллар белән гамәлгә ашырыла торган дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турында карардан тыш, дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турында карар,» сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектына**

# АҢЛАТМА

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проекты «Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2025 елның 20 мартындагы 35-ФЗ номерлы Федераль закон кабул ителүгә бәйле рәвештә эшләнде.

Күрсәтелгән Федераль закон белән, аерым алганда, «Интернет» челтәрендә рәсми сайтта һәркем файдалана алырлык итеп урнаштырыла торган дәүләт мөлкәтен һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру шартлары турындагы мәгълүматлар исемлеге төгәлләштерелгән.

Үзгәрешләрдә каралганча, әлеге исемлектән унитар предприятиене җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятькә үзгәртеп төзү; дәүләт мөлкәтен яисә муниципаль мөлкәтне акционер җәмгыятьләрнең устав капиталларына кертем буларак кертү; Россия Федерациясе территориясеннән читтә акционер җәмгыятьләрнең дәүләт милкендәге акцияләрен сату һәм ышанычлы идарә нәтиҗәләре буенча акционер җәмгыятьләр акцияләрен сату ысуллары белән гамәлгә ашырыла торган хосусыйлаштыру шартлары турында карарлар төшереп калдырыла.

Закон проекты белән охшаш үзгәрешләрне Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруны мәгълүмати тәэмин итүне регламентлаштыра торган «Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына кертү тәкъдим ителә.

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын**

**ФИНАНС-ИКЪТИСАДЫЙ НИГЕЗЛӘҮ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджеты акчалары исәбеннән каплана торган өстәмә чыгымнар таләп итми.

**«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатылып торырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм бүтән норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарын һәм башка норматив хокукый актларын үз көчләрен югалткан дип тануны, туктатып торуны, үзгәрешләр кертүне яки кабул итүне таләп итми.